Безнен белән бер дулкында бул!

Апрель, 2025


# Чишмә башы

**Җир йөзендә тынычлык, дуслык,мәрхәмәтлелек,гаделлек булсын!**



## Апрель - истәлекле көннәргә бай ай.

**1 апрель.** Һәр ай шикелле апрель ае да 1нче числодан башланып китә. Әмма айның башлану көненең исеме бик җитди түгел – “Көлке көне”. Шушы ук көнне дөньяда «Кошлар көне»н дә билгеләп үтәләр.
2 апрель - Халыкара балалар китабы көне. Бик кызыксынган кешегә 1 класс баласының китап тотырган букчасын күтәреп карарга киң әш итәбез ...
4 апрель - Халыкара Интернет көне. Бу көннең мөһим икәнлеген барыбызга да билгеле. ! Сайтны шуның аша укыйбыз бит.
5 апрель - Дөньякүләм мультфильмнар көне. Бу бәйрәмнең апрель аенда үткәрелүенең сере - 1. Апрельнең исеменнән карагыз . Шушы ук көнне Россия тикшерү органнары көне.
7 апрель - Бөтендөнья сәламәтлек көне. Бер генә көн булса да үзебезгә зыян салмыйча торыйк дисәк -?! Ашамаска, эчмәскә, артыгын эшләмәскә кирәк булып чыга түгелме 7 апрель - «Комсомолец» су асты көймәсе һәлак булган көн (1989 ел).
8 апрель - Хәрби коммисариат хезмәткәрләре көне.
11 апрель - фашист когнцлагерьларыннан тоткыннарны азатиту көне.
12 апрель - бу көнне барыбыз да беләбез! Беренче космонавт Юрий Гагагрин кешелек тарихында беренче булып галәмгә күтәрелде. . Авиация һәм космонавтика көне.
13 апрель - бу көнгә дә бәйрәм бар! -. Бөтендөнья рок-н-ролл көне.
15 апрель - мәдәният хезмәткәрләре безнең бәйрәмнәр аз дисәләр, ялгышалар. . Буген Халыкара мәдәният көне
18 апрель - Халыкара һәйкәлләр һәм тарихи истәлекле урыннар көне 18 апрель - Халыкара радио яратучылар көне.
20 апрель - христиан динен тотучыларның олы бәйрәме - Пасха.
22 апрель - Халыкара Җир көне 22 апрель - кемнәр оныткан-Ленин бабай туган көн! Искә төштеме?!
23 апрель - Халыкара инглиз теле көне.
24 апрель - Халыкара яшьләргә теләктәшлек итү көне.
26 апрель - Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай туган көн 26 апрель - Радиация һәм атом-төш кораллы аварияләрендә һәлак булганнарны искә алу көне (1986 ел, Чернобыль авариясе булган көн).
28 апрель - Халыкара хезмәтне саклау көне.
29 апрель - Халыкара бию көне.
Үзегезнең бәйрәм көнегезне тапмадыгызмы? Борчылмагыз, әле алдагы айларда бәйрәмнәр күп булачак!



*Апрель, апрель...*
*Ярсып-кайнап,*
*Бозлар аккан ай да ул.*
*Апрель, апрель...*
*Җылы яктан*
*Кошлар кайткан ай да*
*ул.*
*Апрель, апрель...*
*Чәчкәләрне*
*Сагынып көткән ай да.*

*Апрель, апрель...*
*Халкыбызны*
*Тукайлы иткән ай да!*
*Апрель, апрель...*
*Ләйсән яңгыр*
*Яуган тәүге яз ае.*
*Апрель, апрель...*
*Җан-тәннәрне*
*Иркәләгән наз ае!*

# Апрель ае-Тукай ае



Апрель ае – бөек шагыйребезнең туган ае, шигърият ае. Зәңгәр күк йөзендә кояш балкыган чакта шаулап-гөрләп апрель ае килгәндә, безнең яраткан шагыйребез Г.Тукай туган. Рус халкының Пушкин вә Лермонтовы кебек үк безнең Тукаебыз да үзенең кабатланмас иҗаты белән бөек һәм данлы.

*Тукай көне.*

*Һәр ел саен үзгәрелә...*
*Һәр ел саен Тукай гына*
*Ямь-яшь хәлдә килә безгә.*
*Киңлекләргә язгы аваз-*
*Чыр-чу килә кошлар иле,*
*Чеңләп тора аһәңнәре:*
*Тукай көне!*
*Тукай көне!*

# Без- Тукай оныклары



## Сыерчыклы балачак язым

*Сез елның кайсы фасылын яратасыз? Ә мин язны яратам. Язның да кар эреп, бөреләр бүрткән, тал песие инеш буйларын бизәп, хуш ис сипкән вакытын, дөньяның акрын-акрын ачык яшел төскә бизәлә башлаган чорын яратам. Табигатьнең бераз ял итеп, яңа көч җыеп, кабат яшәрә башлаган мәле бу. Урамнан керәсе килми, өйгә кереп китсәм, язның тагын ниндидер бер матур, серле күренешен күрми калырмын кебек тоела.*

*Зәңгәр күктә яраткан кошларым - сыерчыклар тирбәлә. Кап-кара күгелҗем төстәге бу затлы кошларны мин түземсезлек белән көтеп алам. Агачларга, ут чыбыкларына кунган сыерчыкларны күрсәм, сөенечем эчемә сыймый. Ояга да килсә...миннән дә бәхетле кеше юк!*

*Узган язда сыерчыкларны каршы алырга без кыш уртасыннан әзерләндек. Яңа оя ясау максаты белән, яңа такталар сатып алдык, оя читенә куярга бизәкләр әзерләдек. Кошлар килгәнче үк безнең оя агачта эленеп тора иде инде.*

*Сыерчыкларны мин мәктәпкә барганда, күршеләрнең юкә очында күрдем. Сызгырыпмы-сызгыралар. Гүя: " Без кайтып җиттек, безне күрәсезме, каршы алырга чыгыгыз!"- дияләр кебек. Кызык бит, Рөстәм абыйларга килгәннәр, безнең өй каршысында ник берсе күренсен. Мәктәп каршында бөдрәләнеп утырган каеннарның да кайберләрендә оялар сайлаган сыерчыклар. Димәк, акрынлап киләләр, мин кайтышка, һичшиксез, безнең оя да буш булмаячак!*

*Дәресләр беткәч, өйгә ашыктым. Ни күзем белән күрим, яңа ояның кыегында чем кара ике сыерчык, сары томшыкларын суза-суза, өзелеп-өзелеп сайрап утыра. Сөенечемнән кулларымны чәбәкләп, сикереп тә куйдым. Мондый матур күренешне ничек инде истәлеккә калдырмыйсың ди! Кулыма телефонымны алып, аларны сурәткә һәм видеога да төшердем.*

*Берничә көннән иске оялар да сыерчыклы булды. Алар көннәр буе тырыша-тырыша ояларын төзәттеләр, йомырка салып, нәни кошчыклар чыгардылар. Кошчыкларны ашаттылар, тәрбияләделәр, очарга өйрәттеләр. Мин дә буш тормадым. Аларны, аулау нияте белән йөргән явыз мәчеләрдән, әрсез каргалардан сакладым.*

*Бертуктамый очып, җим ташучы сыерчыкларны күзәтеп, кызгандым мин. Көненә ничә чакрымнар җыялар икән алар? Канатлары, авызлары арымый микән?*

*Җәй уртасында оялар бушады. Сыерчыкларым урманнарга очып китте. Бакчалар, ишегалды күңелсезләнеп калды. "Бәлки эләктереп булыр",- дип утырган мәчеләрнең дә соңгы өметләре өзелде. Оя астына бер- ике көн килеп карадылар да, башка күренмәделәр.*

*Тиздән, бик тиздән ямьле яз кабат киләчәк. Ояларны чистартып, ямьсезләнгән урыннарын төзәтеп куяр вакытлар җитте. Сыерчыкларым гына туган ояларына озын авыр юлларны югалтуларсыз очып, исән – имин кайтып җитсеннәр!*

*Шакирова Ралинә.*

***Без-Тукай оныклары.***

*Әкият, шигырьләрең аша*
*Күпме тәрбия алдык без.*
*Бик күп иҗат җимешләрең*
*Инде яттан беләбез.*
*Синең йөргән сукмаклардан*
*Менә без дә йөрибез.*
*"Туган тел"не,"Тәфтиләүне"*
*Рәхәтләнеп көйлибез.*
*Һәр тарафта горурланып*
*Без дә әйтә алабыз:*
*Без-Тукайның оныклары,*
*Тукай безнең бабабыз.*

***Шакирова Ралинә***

***Эшлекле шәкерт.***

*Әйдәле,Акбай,өйрән син-*
*Арт аягың берлә тор!*
*(Г.Тукай)*

*Арт аягында торырга*
*Акбай күптән өйрәнде.*
*Хәзер аның,Тукай абый,*
*Юк белмәгән һөнәре.*
*Әле менә күптән түгел,*
*Компьютер да алды.*
*Контактта аралашып,*
*Үз яшьтәшләрен тапты.*
*Су анасы,Шүрәле дә*
*Аңа көн дә язалар*
*Җылы матур сүзләр белән*
*Сине искә алалар.*
*Кичә күрдем,ачкан икән,*
*Акбай үз сайтын да.*
*Ышан,тиздән күтәрер ул*
*Илебезнең данын да!*

***Шакирова Ләйсән***

***Балачак.***

*Әй,балачак,балачак,*
*Иң күңелле,рәхәт чак.*
*Уйнап,көлеп,шаярып,*
*Мәңге истә калачак.*
*Балачакның мизгелләре*
*Нигә тиз уза икән?*
*Балачакның кадерен белик*
*Кайтарып булмас бүтән.*
*Әй,балачак,балачак,*
*Иң матур һәм гүзәл чак.*
*Әти-әни кочагында*
*Иркәләнеп үскән чак.*

***Нургалиева Зәмирә***

# Ял итеп алыйк

## Тукайның кайсы әсәре яшеренгән ?








# Башваткычлар

1. ***«Кәҗә белән Сарык» әкиятендә Кәҗә Сарыкны кем диеп йөртә?***
2. ***Су анасы яшәгән урын.***
3. ***Хуҗаларыннан чыгып киткәндә, Кәҗә белән Сарык үзләре белән нәрсә алалар?***
4. ***Кәҗә белән Сарыкны бүреләр күргәч, нинди ризыкка ит таптык дип куаналар?***
5. ***Әй юләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы ...***